**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МОНАСТЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 54-5-20, факс 54-5-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 .11. 2021** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең Лаптевка торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Монастырское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Лаптевка авылы, Гагарин урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан Лаптевка авыл клубы бинасында 2021 елның 30 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең Лаптевка торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге Лаптевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

Лаптевка т. п.».

«КАРШЫ» “РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларының барлыкка килүен һәм таралуын кисәтү өчен

профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны (COVID-19) үтәүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **А.А. Васин**